**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Тинчәле авыл җирлегенең Яңа Тинчәле авылында гражданнар җыены карары**

01 ноябрь 2023 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Тинчәле авыл җирлегенең Яңа Тинчәле авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2024 елда Яңа Тинчәле авыл җирлегенең Яңа Тинчәле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 300 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- Яңа Тинчәле авылында кышкы чорда юлларны тоту, җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү), көнкүреш каты калдыкларын туплау мәйданчыгын төзекләндерү, хуҗасыз хуҗалыкларны коймалауга юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Яңа Тинчәле авыл җирлегенең Яңа Тинчәле авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Тинчәле авыл җирлеге башлыгы _________ Р.К. Мадышев

Гражданнар җыены секретаре _________ Г.Ш. Хәсәнова